РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

№ 48

2018 елның 28 ноябре

**«Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең шәһәр төзелешен проектлаштыруның жирле нормативларын раслау турында» 2017 елның 15 сентябрендәге 24нче номерлы Түбән Кама шәһәр Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 29.4 маддәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 маддәсе нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1.«Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең шәһәр төзелешен проектлаштыруның җирле нормативларын раслау турында» 2017 елның 15 сентябрендәге 24нче номерлы Түбән Кама шәһәр Советы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

5.2.27 пунктында «чикләр» сүзен төшереп калдырырга;

6.3.12 пунктының 6 абзацында «балык саклау зоналары» сүзен төшереп калдырырга;

7.2.7.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"7.2.7.3 Торак пункт чикләре артында урнашкан һәм файдалы казылма ятмалары мәйданнарында торган җир кишәрлекләрен төзү, шулай ук файдалы казылма ятмалары урыннарындагы торак пункт чикләре артында җир асты корылмаларын урнаштыру Татарстан Республикасы буенча Җир асты байлыкларыннан файдалану идарәсе рөхсәте белән рөхсәт ителә.»

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин